ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 79 от «27» 02 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы «Шәһәр хуҗалыгы»
муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан
күрсәтелә торган «НОКРАТ» пляж комплексы
хезмәтләренә һәм мунча хезмәтләренә
тарифлар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә эшен оештыру принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 17 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2016 елны 08 апрелендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль предприятие һәм учреждениеләре тарафыннан күрсәтелүче хезмәтләргә һәм эшенә тарифларны билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында», 5-6 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Шәһәр хуҗалыгы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган «НОКРАТ» пляж комплексы хезмәтләренә һәм мунча хезмәтләренә тарифларны кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 21 декабрендәге 434 номерлы карарын үз көчен югалтты дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының матбугат һәм массакүләм чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының www.mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2024 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Х. Әгъләмовка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов

0000012...

Мамадыш муниципаль
районы Башкарма комитетының
27.02. 2024 ел, № 79 нче
карарына 1 нче кушымта

«НОКРАТ» пляж комплексы хезмәтләренә һәм мунча хезмәтләренә тарифлар

<table>
<tr><th>Күрсәтелүче хезмәтнең исеме</th><th colspan="2">Халык категориясе</th><th>1 кешегә хезмәттән файдалану дәвамлылыгы</th><th>Тариф күләме, сумнарда</th></tr>
<tr><td rowspan="7">Мунчада юыну</td><td colspan="2">14 яшьтән алып пенсия яшенә кадәрге категория</td><td>1 сәгать</td><td>200</td></tr>
<tr><td colspan="2">7 яшьтән алып 14 яшькәчә булган балалар</td><td>1 сәгать</td><td>170</td></tr>
<tr><td colspan="2">Барлык категория пенсионерлар</td><td>1 сәгать</td><td>170</td></tr>
<tr><td colspan="2">7 яшькә кадәрге балалар, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләре</td><td>1 сәгать</td><td>түләүсез</td></tr>
<tr><td colspan="2">Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылар</td><td>1 сәгать</td><td>түләүсез</td></tr>
<tr><td rowspan="2">«Надежда» балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют ДКУ</td><td>7 яшькә кадәрге балалар</td><td>1 сәгать</td><td>60</td></tr>
<tr><td>7 яшьтән алып 14 яшькәчә булган балалар</td><td>1 сәгать</td><td>200</td></tr>
<tr><td rowspan="4">«НОКРАТ» пляж комплексы хезмәтләре</td><td colspan="2">Өлкәннәр һәм 14 яшьтән алып балалар</td><td>2 сәгать</td><td>400</td></tr>
<tr><td colspan="2">7 яшьтән алып 14 яшькәчә булган балалар</td><td>2 сәгать</td><td>200</td></tr>
<tr><td colspan="2">7 яшькә кадәрге балалар</td><td>2 сәгать</td><td>түләүсез</td></tr>
<tr><td colspan="2">Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннар</td><td>2 сәгать</td><td>түләүсез</td></tr>
</table>